# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җерлеге
Сәпәй авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**03 ноябрь 2023 ел** **№1**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Уставы нигезендә 2023 елның 03 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыеннары (җыен) нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының йомгаклау протоколы төзелде:

«Сез, 2024 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, махсус хәрби операциягә киткән мобилизацияләнгән гаилә әгъзасы, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар өчен 175 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Сәпәй торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 350 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Урам челтәрләрен тышкы яктыртуны тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергияне сак тотучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм хезмәт күрсәтү);
- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (кар җыештыру);
- Халыкның күпләп ял итү урыннарын (паркларны, балалар өчен уен мәйданчыкларын һәм халыкның күпләп ял итә торган башка урыннарны) төзү, ремонтлау һәм аның янәшәсендәге территорияне төзекләндерү (чүп үләннәрен чаптыру, чүп-чар җыю);
- Традицион урыннарны ремонтлау, киртәләр кору, традицион каберлекләрне төзекләндерү (печән чаптыру, куакларны кисү).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 424 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 377.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 377, «КАРШЫ» » позициясе өчен 0 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Сәпәй торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә (дөрес) дип танырга.
2. Түбәнәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга:

«Сез, 2024 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, махсус хәрби операциягә киткән мобилизацияләнгән гаилә әгъзасы, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар өчен 175 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Сәпәй торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 350 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Урам челтәрләрен тышкы яктыртуны тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергияне сак тотучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм хезмәт күрсәтү);

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (кар җыештыру);

- Халыкның күпләп ял итү урыннарын (паркларны, балалар өчен уен мәйданчыкларын һәм халыкның күпләп ял итә торган башка урыннарны) төзү, ремонтлау һәм аның янәшәсендәге территорияне төзекләндерү (чүп үләннәрен чаптыру, чүп-чар җыю);

- Традицион урыннарны ремонтлау, киртәләр кору, традицион каберлекләрне төзекләндерү (печән чаптыру, куакларны кисү).

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Сәпәй авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakayevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сәпәй авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Сәпәй авыл җирлеге башлыгы — Ф.Г.Галиева

САПЕЕВСКИЙ СОВЕТ СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1643002485
КПП 164301001